# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ ПӘНӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## К А Р А Р

**№ 73** **30 сентябрь 2022 ел.**

**«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларынын, сайланулы вазыйфаи затларның, Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре, белгечләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 23 апрелендәге 122 номерлы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында»**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы (2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы закон), Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларынын, сайланулы вазыйфаи затларның, Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре, белгечләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 23 апрелендәге 122 номерлы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы карарына (2018 елның 14 маендагы 96 номерлы, 2018 елның 22 ноябрендәге 125 номерлы, 2018 елның 30 ноябрендәге 128 номерлы, 2020 елның 12 сентябрендәге 186 номерлы, 2021 елның 31 декабрендәге 45 номерлы карарлар нигезендә кертелгән өстәмәләр һәм үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларның, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре, белгечләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары

турында нигезләмәнең 2.2 пунктында «11498 сум» сүзләрен «11958 сум» сүзләренә алмаштырырга.
1.2. Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларның, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре, белгечләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2 кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә:
"Югары Пәнәче авыл җирлеге башлыгының акчалата түләү күләме";

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 16389 |

1.3. Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче җирле үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларның, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре, белгечләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.14 пунктында «11498 сум» сүзләрен «11958 сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар 2022 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

4. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә локаль актларны әлеге нигезләмәгә туры китерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе, Югары Пәнәче авыл җирлеге башлыгы** **М. Х. Туктаров**